ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Югары Ослан муниципаль районында аукцион рәвешендә үткәрелә торган сатуларда арендага муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 729 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 23 декабрендәге 961 номерлы карарын кабул итүгә бәйле рәвештә Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә үткәрелә торган торгларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын» расларга.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 августындагы 1093 номерлы “Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында”гы карарын үз көчен югалткан дип таныырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С.Хәкимҗанов

2018-301